**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 25 гыйнвар № 22

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары һәм укучылары туклануының көндезге рационы кыйммәтен һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен нормативлар билгеләү турында» 2015 ел, 19 октябрь 780 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 26 октябрь, 786 нчы һәм 2016 ел, 28 декабрь, 1021 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендәге дәүләт учреждениеләренең көндезге формада фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программасы буенча укучы һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы аспирантларына дәүләт стипендиясен 6 000 сум күләмендә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары туклануының көндезге рационы кыйммәтен һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен нормативларны билгеләү турында» 2016 ел, 26 октябрь, 786 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә «студентлары» сүзен «укучылары» сүзенә алмаштырырга;

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендәге дәүләт учреждениеләренең көндезге формада фәнни-педагогик кадрлар әзерләү

программасы буенча укучы һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы аспирантларына дәүләт стипендиясен 6 000 сум күләмендә.».

3. Әлеге карарның 1 нче пункты гамәле – 2016 елның 29 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә, 2 нче пункты гамәле 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\22.docx